МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.07.2015 г.Казань № 317

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга яраштыру максатында, һәм шулай ук «Хуҗалык җәмгыятьләренең мөһерләре булуының мәҗбүрилеген юкка чыгару өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289нчы, 2015 елның 19 мартындагы 134нче боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Административ регламент).

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлегенә (Т.А.Апаевка) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне министр урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
03.07.2015 № 317

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

Административ регламентның 1 бүлегендә:

1.3 пункты 1.3.4 пунктчасының «1)» пунктын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Мәгълүмат такталарына урнаштырылган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) мәгълүматларны үз эченә ала;»;

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләргә ярашлы гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Салым кодексына (икенче өлеш) (алга таба – РФ Салым кодексы) (РФ Законнары җыелмасы, 07.08.2000, № 32, 3340 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнары җыелмасы, 29.12.2008, № 52 (1 өлеш), 6249 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнары җыелмасы, 02.08.2010, № 31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Аерым эшчәнлек төрләренә лицензия бирү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 99-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнары җыелмасы, 09.05.2011, № 19, 2716 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кара металл калдыкларын эшкәртү һәм аларны юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 369нчы

карарына (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 369нчы карары) (РФ Законнары җыелмасы, 21.05.2001, № 21, 2083 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төсле металл калдыкларын эшкәртү һәм аларны юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 370нче карарына (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 370нче карары) (РФ Законнары җыелмасы, 21.05.2001, № 21, 2084 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензиянең типлаштырылган формасын раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826нчы карарына (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 826нчы карары) (РФ Законнары җыелмасы, 17.10.2011, № 42, 5924 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кара һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1287нче карарына (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1287нче карары) (РФ Законнары җыелмасы, 17.12.2012, № 51, 7222 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик затлардан кабул итү тыелган, көнкүрештә яраксыз кара металл калдыкларының исемлеген раслау турында» 2003 елның 11 сентябрендәге 486нчы карарына (алга таба – ТР МКның 486нчы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, октябрь 2003, № 19, 59 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сораулары» турында 2007 елның 23 июлендәге 325нче карарына (алга таба – ТР МКның 325нче карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.08.2007, № 30, 1057 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик затлардан кабул итү рөхсәт ителгән төсле металл калдыклары исемлеген раслау турында» 2001 елның 19 ноябрендәге 812нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 27 мартындагы 190нчы карарына (алга таба – ТР МКның 190нчы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 16.04.2008, № 14, 0528 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым

карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010 № 46, 2144 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламенты» 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгына (алга таба – Контроль буенча административ регламент) (Республика Татарстан, 07.05.2013, № 68; Ватаным Татарстан, 21.05.2013, № 75, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).»;

түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт белән тулыландырырга:

«1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата - Министрлык тарафыннан ясалган һәм документка кертелгән мәгълүматның (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) әлеге мәгълүмат чыганагы булган документтагы мәгълүматка туры килмәвенә китергән хата (язгандагы хата, басмадагы хата, грамматик яисә арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны - муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм тапшыру, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү тәрәзәсе.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба - гариза) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап язган гарызнамә күз уңында тотыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсе, 1 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1- 3нчы кушымталар).»;

Административ регламентның 2 бүлегендә:

графаларның исемнәрен түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | |
|---|---|---|
| «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең исеме | Стандартка карата таләпнең эчтәлеге | Таләпне яисә хезмәт күрсәтүне билгеләүче норматив акт»; |

2.2 пунктының исемен («Стандарт таләбенең исеме» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме»;

2.4 пунктының исемен («Стандарт таләбенең исеме» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүнең кирәклеген исәпкә алып; туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте

күрсәтүне туктату срогы»;

2.5 пунктын («Стандарт таләбенең эчтәлеге» графасы) түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүләр юк.»;

2.6 пунктының исемен («Стандарт таләбенең исеме» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Норматив хокукый актларга ярашлы рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында һәм гариза бирүче аларны күрсәтергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге, һәм шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; карамакларында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма;

2.13 пунктының исемен («Стандарт таләбенең исеме» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада, гариза бирүченең гарызнамәсен теркәү срогы»;

2.14 пунктының исемен («Стандарт таләбенең исеме» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең кәтү һәм аларны кабул итү урыннарына, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматларны эшләү һәм урнаштыруга карата таләпләр»;

2.15 пунктының исемен («Стандарт таләбенең исеме» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең ачыклыгы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара эш итү саны һәм аларның дәвамлылыгы»;

2.15 пунктын («Стандарт таләбенең эчтәлеге» графасы) түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац белән тулыландырырга:

«Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүмат mert.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (электрон формада хезмәт күрсәтүне сорап, гариза тапшырылган очракта), КФҮтә (КФҮ аша хезмәт күрсәтүне сорап, гариза тапшырылган очракта) алына ала.»;

2.16 пунктының исемен («Стандарт таләбенең исеме» графасы) түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: «, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең купфункцияле үзәкләренең ерактагы эш урыннарында»;

2.16 пунктын («Стандарт таләбенең эчтәлеге» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактагы эш урыннарында алганда консультация бирү, документларны кабул итү һәм тапшыру (гариза бирүченең теләге буенча) эшләрен КФҮ белгече, КФҮнең ерактагы эш урыннарындагы белгечләр башкара.»;

Административ регламентның 3 бүлегендә:

3 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, һәм шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең купфункцияле үзәкләрендә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 пунктчасында «4» санын «5» саны белән алыштырырга;

3.9 пунктының исемен «һәм КФҮнең ерактагы эш урыннары» сүзләре белән тулыландырырга;

3.9.1 пунктчасын «, КФҮнең ерактагы эш урыннары.» сүзләре белән тулыландырырга;

3.9.2 пунктчасын, «КФҮ аша» сүзләреннән соң, «һәм КФҮнең ерактагы эш урыннары» сүзләре белән тулыландырырга;

3.9.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.9.3. КФҮтән һәм КФҮнең ерактагы эш урыннарыннан дәүләт хезмәте алуга документлар килгәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.8 пунктларына ярашлы рәвештә башкарыла. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе КФҮкә һәм КФҮнең ерактагы эш урыннарына юллана.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.10 пункты белән тулыландырырга:

«3.10. Техник хаталарны төзәтү.

3.10.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата табылганда, гариза бирүче бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4нче кушымта);

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә тапшырылган,

техник хата булган документ;

техник хата булуын дәлилләүче юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турындагы гариза кәгазьдә яисә почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу турында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат формасында гариза бирүче тарафыннан юллана.

3.10.2. Эшләр башкару бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, беркетелгән документлар белән бергә гаризаны терки һәм бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, гариза теркәлгәннән соң, бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгәннән соң, бүлек белгеченә каралуга юлланган гариза.

3.10.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында, кул куйдырып һәм техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып, министр (министр урынбасары) имзалаган төзәтелгән документны гариза бирүчегә тапшыра яисә почта элемтәсе аша гариза бирүченең адресына техник хатасы булган документның төп нөсхәсен бүлеккә тапшырган очракта төзәтелгән документны алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, техник хата табылганнан яисә хата табылуы турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алынганнан соң, өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.»;

Административ регламентның 4 бүлеге исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары»;

Административ регламентның 1 – 3нче кушымталарын түбәндәге эчтәлекле искәрмә белән тулыландырырга: «Искәрмә. Мөһер – булганда.»;

Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын түбәндәге эчтәлекле 4нче кушымта белән тулыландырырга:

«Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә ясалган хата турында хәбәр итәм: ___________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:_____________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:______________________________________________________

_____________________________________________________________________

Документта җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәртүләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Лицензияләү сораулары буенча вәкаләтле хезмәткәр________________________
(вазыйфа исеме, Ф.И.О., телефон)

Юридик зат җитәкчесе
(шәхси эшкуар) ________________ ________________
(имза, мөһер) (ФИО)

Искәрмә. Мөһер – булганда.»;

Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4нче кушымтаны Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5нче кушымта дип санарга.